# Шагыйрьнең “Күңел сандыгы”

Декабрь аеның 11 нче көнендә Бәзәкә авылында туып үскән шагыйрь Марсель Гыйльфан улы Гыймазетдиновның тууына 78 ел тулды. Безнең горурлыгыбыз булган якташыбызны искә алу, аның якты ижатын таныту максатында авыл китапханәсендә һәрдаим төрле чаралар үткәрелеп килә. Бу юлы талантлы авылдашыбыз ижаты белән танышу өчен чарага урта мәктәпнең башлангыч сыйныф укучылары чакырылды.

“Күңел сандыгы” дип исемләнгән әдәби кичәне ачып Бәзәкә китапханәчесе Ф.Бәшәрова укучыларны шагыйрьнең тормыш юлы, нәшер ителгән шигырь җыентыклары – “Яшәү мәгънәсе”, “Язлардан алалмыйм күземне”, “Син мине белмисең” дигән китаплары, ижатындагы төп темалар белән таныштырды. Видеоязмадан М.Гыймазетдиновның төрле кичәләрдә үзе укыган шигырьләрен, аны татар дөньясына таныткан һәм көннән-көн популярлаша барган җырларын укучылар бирелеп тыңладылар. Кичәне дәвам итеп катнашучылар “Син мине белмисең” дигән җыентыктан шәфкатьлелек, намус, сагыну, ярату, соклану турындагы шигырьләрен укып шагыйрьнең “Күңел сандыгы”нда нинди хисләр саклanganын ачыкладылар. Аның шигырьләрен укып, тыңлап киткән яшь буын да бу хисләрне үз күңеленә салыр дип ышанасы килә. Әдәби кичә шагыйрьнең истәлегенә авыл китапханәсендә эшләнгән

**“Шигырем һәйкәл, җырым маяк булса иде,**
**Алга әйдәп алып барырлык”**

дигән стенд янында фотога төшү белән тәмамланды.

*Ф.Бәшәрова*


Шигырем һәйкәл, җырым маяк булса иде,
Алга әйдәп алып барырлык.
Туган җирнең яме, яшеллеге тәме
Тамыр җәйгән безнең йөрәктә.
Тик бәхетле була кеше туган якта –
Аңладым мин чит җирләрдә шушы хакта.
Әйләнеп авылга кайт та син,
Шифалы җилләрен үп әле...
Ә яшәү нинди шәп – күр әле!
Шатлык булып җиргә таныйк без...
Үлгәннәрнең йөрәкләре тибә
Мәңгелек ут булып мәйданда.
Шәфкатьлелек мирас булып барсын,
Без киткәч тә килер буынга.
Шагыйрь Марсель Гыйльфан улы
Гыймазетдинов
1943-1993


здесь
живет
сказка


Шигырем һәйкәл, җырым маяк
Алга әйдәп алып барырлык.